**IV ЧАКЫРЫЛЫШ ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӨСЛИМ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ МЕТРӘЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫНЫҢ XLIX УТЫРЫШЫ**

# КАРАР № 80

2024 ел «28» май

**Физик затларның җирле салымнар суммалары өлешендә бурычны түләтүгә ышанычсыз дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләү турында**

Россия Федерациясе Салым кодексының 59 статьясындагы 3 пункты, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Региональ салымнар суммалары өлешендә бурычны түләтүгә ышанычсыз дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләү турында» 2024 елның 12 апрелендәге 18-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Метрәй авыл җирлеге Советы **КАРАР БИРДЕ:**

1. Физик затларның җирле салымнар суммалары өлешендә бурычны түләтүгә ышанычсыз дип тануга өстәмә нигезләр билгеләргә:

1) варислар мирас хокукыннан баш тарткан, варислар булмаган яки мирас ачылганнан соң бер ел эчендә мирасны кабул итмәгән очракта үлгән яки үлгән дип игълан ителгән физик затларда бурычлар булу;

2) 2024 елның 1 гыйнварына кадәр гамәлдән чыгарылган җирле салымнар буенча оешмаларга яки шәхси эшмәкәрләргә исәпләнгән бурычлар булу;

3) физик затларның Россия Федерациясе Салым кодексының 48 статьясында билгеләнгән сроклар тәмамланганнан соң 500 сумнан артмаган суммада бурычы булу.

2. Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Метрәй авыл җирлеге Советының 2023 елның «17» маендагы 62 номерлы «Җирле салымнар суммалары өлешендә бурычларны түләтүгә ышанычсыз дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләү турында» гы карарын гамәлдән чыгарырга.

3. Әлеге карарны Мөслим муниципаль районы Метрәй авыл җирлегенең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында игълан итәргә һәм «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

4. Әлеге карар рәсми рәвештә игълан ителгәннән соң үз көченә керә һәм 2024 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә үз көчен җәелдерә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Метрәй Авыл җирлеге башлыгы Шамгунов И.В.